**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.01.2019 Балык Бистәсе штп. № 36пи

Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәтнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентын раслау турында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 маддәсе, 2010 елның 27 июлендәге “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 880 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 21 июнендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында” 96пи номерлы карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәтнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең кушымта итеп бирелә торган Административ регламентын расларга.

2. Көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 15 октябрендәге 242пи номерлы карары белән расланган капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәтнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Административ регламентын.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2019 елның 29 гыйнварындагы
36 пи номерлы карарына
кушымта

**Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәтнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Административ регламенты**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге Административ регламенты (алга таба – Регламент) капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәтнамә бирү буенча муниципаль (үзидарәлек) хезмәт күрсәтүнең (алга таба – муниципаль хезмәт) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Хезмәтне алучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).

1.3.Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан бирелә (алга таба – Башкарма комитет).

Муниципаль хезмәт күрсәтүне башкаручы – Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы бүлеге (алга таба – Бүлек).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: РТ, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48 йорт.

Бүлекнең урнашу урыны: РТ, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48 йорт.

Эш графигы:

дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

Ял һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән тәгаенләнә.

Белешмә телефоны: (884361)2-22-96;

Башкарма комитет бинасына үтү шәхесне таныклаучы документлар буенча гамәлгә ашырыла.

1.3.2.Балык Бистәсе муниципаль районының (алга таба – муниципаль район) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – “Интернет” челтәре) рәсми сайтының адресы: www.ribnaya-sloboda.tatarstan.ru.

1.3.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү, шулай ук Бүлекнең урнашу урыны һәм эш графигы турында мәгълүматны алырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен муниципаль хезмәт күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны эченә алган Башкарма комитет бүлмәләрендәге мәгълүмат стендлары ярдәмендә.

Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган үзидарәлек хезмәте турындагы мәгълүматларны үз эченә ала.

2) муниципаль районның Интернет челтәрендәге www.ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. рәсми сайты ярдәмендә;

3) Татарстан Республикасының https://uslugi.tatarstan.ru дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр Порталында;

4) http:// www.gosuslugi.ru Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталында.

5)Башкарма комитетта (Бүлектә):

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яисә телефон буенча;

язма рәвештә (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә – почта аша кәгазь йөрткечтә, электрон почта буенча электрон рәвештә.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан муниципаль районның рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләргә нигезләнеп гамәлгә ашырыла:

2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы закон – Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы (алга таба – РФ ШтК) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 03.01.2005, №1 ( 1 өлеш), 16 маддә);

2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы закон – Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ Җир кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 29.10.2001, №44, 4147 маддә);

2000 елның 1 августындагы 117-ФЗ номерлы закон – Россия Федерациясе Салым кодексы (икенче кисәге) (алга таба – РФ СК) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 07.08.2000, №32, 3340 маддә);

1995 елның 17 ноябрендәге “Россия Федерациясендә архитектура эшчәнлеге турында” 169-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 169-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 20.11.1995, №47, 4473 маддә);

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” №131-ФЗ номерлы Федераль закон (РФ законнары җыентыгы, 06.10.2003, № 40, 3822 маддә);

2010 елның 27 июлендәге “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 210-ФЗ номерлы Федераль закон (РФ законнары җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә) (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2015 елның 19 февралендәге “Төзүгә рөхсәтнамә рәвешен һәм объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтнамә рәвешен раслау турында” 117/пр номерлы боерыгы (алга таба – 117/пр номерлы боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 13.04.2015);

Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Законы (алга таба – 45-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы, №155-156, 03.08.2004);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 27 сентябрендәге “Төзүгә рөхсәтнамә һәм объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтнамә бирү өчен зарури документларны электрон рәвештә җибәрү турында” 729 номерлы карары (РФ законнары җыентыгы, 20.10.2017, N 728, 4162 маддә)

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2015 елның 3 апрелендә XLVIII-1 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав) (Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы http://pravo.tatarstan.ru, 29.05.2015);

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 12 ноябрендәге XLI-8 номерлы карары белән расланган Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – БК турында Нигезләмә);

Башкарма комитетның 2016 елның 29 февралендәге 07ри номерлы боерыгы белән расланган Бүлек турында Нигезләмә (алга таба – бүлек турында Нигезләмә);

Башкарма комитет җитәкчесенең 2015 елның 19 гыйнварындагы 03-ри номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге атамалар (терминнар) һәм билгеләмәләр файдаланыла:

- гариза бирүче (заявитель) – телдән, язма яки электрон рәвештә Идарәгә үзидарәлек хезмәте күрсәтү турында запрос белән мөрәҗәгать итүче физик яки юридик затлар (дәүләт органнары һәм аларның территориаль органнарыннан, дәүләт бюджеттан тыш фондлары органнары һәм аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан гайре) яисә аларның вәкаләтле вәкилләре;

- төзүче (застройщик) – үзенеке булган җир кишәрлегендә төзүне, реконструкцияләү, капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлауны, шулай ук инженерлык тикшеренүләре башкаруны, аларны төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау өчен проект документациясен әзерләүне гамәлгә ашыручы физик яки юридик зат;

-техник заказ бирүче (технический заказчик) – профессиональ нигездә эш итүче физик зат яки төзүче тарафыннан вәкаләт бирелгән юридик зат, төзүче исеменнән инженерлык эзләнүләрен башкару турында, проект документациясе әзерләү турында, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау турында шартнамәләр төзи, күрсәтелгән эш төрләрен үтәүгә заданиеләр әзерли, инженерлык эзләнүләрен башкаручы һәм (яки) проект документациясен әзерләүне гамәлгә ашыручы, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлауны башкаручы затларга күрсәтелгән эш төрләрен үтәү өчен материаллар һәм документлар бирә, проект документациясенраслый, капиталь төзелеш объектларын кулланылышка кертүгә рөхсәт алу өчен кирәкле документларны имзалый, әлеге Кодекста күздә тотылган башка функцияләрне гамәлгә ашыра. Төзүче техник заказ бирүче функцияләрен мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашырырга хокуклы;

Төзүгә рөхсәтнамә капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты белән күздә тотылган барлык, андый рөхсәтнамә төзүнең, реконструкцияләүнең аерым этапларына бирелү очракларыннан гайре, срокка бирелә. Индивидуаль торак төзелешенә рөхсәтнамә ун елга бирелә.

Төзелешкә рөхсәт бирү түбәндәге очракта таләп ителми:

1) физик затка эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру белән бәйләнмәгән максатлар өчен бирелгән җир кишәрлегендә гараж төзү яки җиләк-җимеш бакчачылыгы, дача хуҗалыгы алып бару өчен бирелгән җир кишәрлегендә төзү;

2) капиталь төзелеш объектлары булып тормаучы (киосклар, күтәрмәләр һ.б.) объектларны төзү, реконструкцияләү;

3) җир кишәрлегендә каралты-куралар һәм ярдәмче файдаланудагы корылмалар төзү;

4) капиталь төзелеш объектлары һәм (яки) аларның өлешләрен үзгәртүләр, әгәр андый үзгәртүләр аларның конструкциясенә һәм ышанычлылык һәм куркынычсызлык сыйфатламаларына кагылмаса һәм рөхсәт ителгән төзелеш, реконструкцияләүнең шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән чик параметрларыннан артып китмәсә;

4.1) капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлауның;

5) бүтән очракларда, әгәр Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе субъектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнары нигезендә төзелешкә рөхсәтнамә алу таләп ителмәсә.

Төзелешкә рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогы төзүченең андый рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогы чыкканчыга кадәр алтмыш көннән алда бирелгән гаризасы буенча озайтылырга мөмкин. Төзелешкә рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогын озайту шул очракта кире кагыла, әгәр капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү андый гариза бирү срогы чыкканчы башланмаган булса.

дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ераклашкан эш урыны – 2012 елның 22 декабрендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләрен раслау турында” 1376 номерлы карары белән расланган дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы

муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр яки авыл җирлегендә төзелгән дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү күпфункцияле үзәгенең территория ягыннан аерымланган структура бүлекчәсе (офисы);

техник хата – үзидарәлек хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка кертелгән (үзидарәлек хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсенә) мәгълүматларга тәңгәл булмауга, алар нигезендә кертелгән мәгълүматларның документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китерүче ялгыш (ялгышлык белән җибәрелгән хәреф, сүз хатасы, грамматик яки арифметик хата яисә шуларга охшаш ялгышлыклар).

Әлеге Регламентта үзидарәлек хезмәте күрсәтү турындагы гариза дигәндә (алга таба – гариза) үзидарәлек хезмәте күрсәтү турында таләп аңлашыла (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 маддәсенең 2 пункты). Гариза стандарт бланкка тутырыла (кушымта №1).

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләп исеме | Стандартка таләпләрнең эчтәлеге | Хезмәт яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәтнамә бирү | РФ ШтК ның 51 маддәсенең 1 өлеше;<br>131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсе 20 пункты;<br>ТР ның 45-ЗРТ номерлы Законының 15 маддәсе 20 пункты. |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарәнең башкарма-боеручы органының исеме | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты | БК турында нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | 1. Төзелешкә рөхсәтнамә (кушымта №2).<br>2.Төзелешкә гамәлдә булу срогы озайтылган рөхсәтнамә.<br>3.Төзелешкә кертелгән үзгәрешләр белән рөхсәтнамә.<br>4.Төзелешкә рөхсәтнамәнең кабаттан нөсхәсен (дубликатын) бирү.<br>5.Хезмәт күрсәтүне кире кагу турында хат. | РФ ШтК ның 51 маддәсенең 1, 20, 21.14 өлешләре |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итүнең зарурлыгын исәпкә алып, әгәр туктату мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында күздә тотылган булса, шул очракта муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату | Төзелешкә рөхсәтнамә бирү – гариза биргән көнне дә кертеп 7 көн эчендә.<br>Төзелешкә рөхсәтнамә срогын озайту – биш көн.<br>Төзелешкә рөхсәтнамәгә үзгәрешләр кертү – җиде көн. Төзелешкә рөхсәтнамәнең дубликатын бирү – өч көн.<br>Үзидарәлек хезмәте күрсәтү срогын туктату (туктатып тору) күздә тотылмый. | РФ ШтК ның 51 маддәсенең 11, 21.14 өлешләре |
| 2.5. Үзидарәлек хезмәте күрсәтү өчен законнар яки башка норматив хокукый актлар нигезендә гариза бирүче тапшырырга тиешле зарури документларның, шулай ук үзидарәлек | Капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү очрагында:<br>1) Гариза;<br>2) Җир кишәрлегенә хокук урнаштыручы документлар, шул исәптән сервитут билгеләү турында килешү, ачык сервитут | |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең тулы исемлеге, аларны гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе | билгеләү хакында карар, **әгәр аңа хокук күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса**;<br>3) Проект документациясендәге материаллар (әгәр күрсәтелгән документлар (**аларның күчермәләре яки алардагы мәгълүматлар) билгеләмәләрнең бердәм дәүләт реестрында булмаса**):<br>а)аңлатма язуы;<br>б)планлаштыручы оешманың җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы нигезендә башкарылган капиталь төзелеш объектының урнашу урынын, аңа килү һәм үтү юлларын, ачык сервитут тәэсире (көче) зоналары, археологик мирас объектлары чикләрен билгеләп җир кишәрлеге схемасы;<br>в) планлаштыручы оешманың территорияне планлаштыру буенча документациясе составында расланган линияле объектларга карата кулланылучы кызыл линияләр чикләрендә линияле объектның урнашуын раслаучы җир кишәрлеге схемасы;<br>г) архитектура чишелешләре;<br>д) инженерлык җиһазлары турында мәгълүматлар, проектланучы капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэминат челтәрләренә кушу (технологик тоташтыру) урыннарын билгеләп инженер-техник тәэминат челтәрләренең җыелма планы;<br>е) капиталь төзелеш объектын төзү оешмасы (төзүне оештыру) проекты;<br>ж) капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен җимерү яки сүтеп алу буенча эшләрне оештыру проекты;<br>з)инвалидларның сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял итү, спорт объектларына һәм бүтән социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга, Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсе нигезендә күрсәтелгән объектларның проект документациясенә | |

| | | |
|---|---|---|
| | экспертиза уздырылмау шартында күрсәтелгән объектларны төзү, реконструкцияләү очрагында торак фонды объектларына керү (үтү) мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар исемлеге;<br>4) капиталь төзелеш объекты проект документациясенә экспертизаның уңай бәяләмәсе (Шәһәр төзелеше кодексының 48 маддәсенең 12.1 өлешендә каралган очракта төзелешнең аерым этапларына карата кулланыла торган), әгәр андый проект документациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсе нигезендә экспертиза узарга тиеш булса, Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсенең 3.4 өлешендә каралган очракларда проект документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе, Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсенең 6 өлешендә каралган очракларда проект документациясенә дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсе (**әгәр күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки алардагы мәгълүматлар) билгеләмәләрнең бердәм дәүләт реестрында булмаса**);<br>5)үзгәрешләр кертелгән проект документациясе файдаланылган очракта Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсенең 3.5 өлешендә каралган бәяләмә;<br>6) андый объектны реконструкцияләү очрагында, 6.2 пунктында күрсәтелгән күпфатирлы йортны реконструкцияләү очракларыннан гайре, капиталь төзелеш объектының барлык булган ияләренең ризалыгы;<br>7) реконструкция хокукый иясе булып дәүләт (үзидарәлек) унитар предприятиесе, дәүләт (үзидарәлек) бюджет яки автоном учреждениесе торган ( күрсәтелгән орган аңа карата тиңдәшле рәвештә гамәлгә куючы (оештыручы) функцияләрен һәм вәкаләтләрен яисә мөлкәт милекчесе хокукларын гамәлгә ашыра) дәүләт (үзидарәлек) милкендәге капиталь төзелеш объектында дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), атом энергиясе буенча "Росатом" Дәүләт корпорациясе, космик эшчәнлек буенча "Роскосмос" Дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджеттан тыш фонд идарәсе органы | |

| | | |
|---|---|---|
| | яки җирле үзидарә органы булып торган дәүләт (үзидарәлек) заказ бирүчесе тарафыннан үткәрелгән очракта – андый реконструкцияне үткәрү турындагы, шул исәптән реконструкцияне гамәлгә ашырганда күрсәтелгән объектка китерелгән зыянны каплау шартларын һәм тәртибен тәгаенләүче килешү;<br>8) күпфатирлы йорттагы бүлмә һәм машина урыннары милекчеләренең күпфатирлы йортны реконструкцияләү очрагында торак законнары нигезендә кабул ителгән гомуми җыелышы карары яки, әгәр андый реконструкция нәтиҗәсендә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәт үлчәменең (күләменең) кечерәюе барлыкка килсә, күпфатирлы йорттагы барлык бүлмә һәм машина урыннары милекчеләренең ризалыгы;<br>9) проект документациясенә дәүләтнеке булмаган экспертизаның уңай бәяләмәсе тапшырылганда проект документациясенә дәүләтнеке булмаган экспертизаның уңай бәяләмәсен биргән юридик затның аккредитациясе турында таныклык күчермәсе;<br>10) әгәр мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләр үткәргән очракта андый объектның конструкцияләре һәм ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгының бүтән сыйфатламаларына кагылынса, мәдәни мирас объектлары турында Россия Федерациясе законнарында күздә тотылган документлар.<br>Рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогын озайтканда гариза бирүче тапшыра:<br>1) Төзелешкә рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогын озайту турында гариза (төзелешкә рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогы чыкканчыга кадәр алтмыш көннән алда бирелә).<br>Төзелешкә рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогын озайту турында гариза торак урынын, гражданнарның һәм юридик затларның акча средстволарын күпфатирлы йортны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзүдә өлешләп | |

| | | |
|---|---|---|
| | катнашу өчен тапшыруны күздә тоткан шартнамә нигезендә төзелештә өлешләп катнашуга җәлеп итүче төзүче тарафыннан бирелгән очракта мондый гаризага төзүче тарафыннан төзелештә өлешләп катнашу шартнамәсе нигезендә торак урынны тапшыру буенча йөкләмәләрен тиешенчә үтәү өчен банкның поручительлек шартнамәсе яисә күпфатирлы йорт төзелешендә һәм (яки) (төзүченең) күчемсез мөлкәтенең бүтән объектларын төзүдә өлешләп катнашу өчен акча средстволарын җәлеп итүче затның гражданлык җаваплылыгын иминләштерү шартнамәсе теркәлергә тиеш.<br>Төзелешкә рөхсәтнамәгә үзгәрешләр керткәндә гариза бирүче юллый:<br>Җир кишәрлекләренә хокукның, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукының гариза бирүчегә күчүе, җир кишәрлегенең барлыкка килүе турында реквизитларын күрсәтеп язма рәвештә хәбәрнамә:<br>1) РФ ШтК ның 51 маддәсенең 21.5 өлешендә күрсәтелгән очракта андый җир кишәрлекләренә хокук урнаштыручы документларны;<br>2) РФ ШтК ның 51 маддәсенең 21.6 һәм 21.7 өлешләрендә каралган очракларда җир кишәрлекләрен оештыру турында карарны, әгәр җир законнары нигезендә җир кишәрлеген булдыру карарын дәүләт хакимиятенең башкарма органы яки җирле үзидарә органы кабул итсә;<br>3) капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләүне гамәлгә ашыру планлаштырыла торган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын РФ ШтК ның 51 маддәсенең 21.7 өлешендә күздә тотылган очракта;<br>4) РФ ШтК ның 51 маддәсенең 21.9 өлешендә күздә тотылган очракта җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензияне кабаттан рәсмиләштерү хакында карарны; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 5) капиталь төзелеш объектын төзү очрагында Россия Федерациясе законнары нигезендә объектны урнаштыру белән бәйле рәвештә территорияне файдалануның аерым шартлары белән зона билгеләү яки капиталь төзелеш объектын реконструкцияләү очрагында аның нәтиҗәсендә реконструкцияләнгән объектка карата территорияне файдалануның аерым шартлары белән зона билгеләү яисә элек билгеләнгән территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона үзгәртелергә тиеш булганлыктан территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона билгеләү яки аны үзгәртү турында карар күчермәсе.<br>Рөхсәтнамәнең дубликатын биргәндә:<br>1) Гариза;<br>2) Шәхесне яки вәкаләтләрне таныклаучы документлар.<br>Үзидарәлек хезмәтен алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Башкарма комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм теркәлүче документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазь йөрткечләрдә түбәндәге ысулларның кайсы да булса берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш йөртүче зат тарафыннан);<br>почта аша җибәрү.<br>Гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан шулай ук көчәйтелгән югары квалификацияле электрон култамга белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми керү мөмкинлеге булган мәгълүмати-телекоммуникация челтәре, шул исәптән Интернет мәгълүмати- телекоммуникация челтәре һәм дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләренең Бердәм порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә зарур булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хаклы документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма. | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:<br>Индивидуаль торак төзелеше объекты булмаган объектлар төзүгә рөхсәтнамә бирү очрагында:<br>1) Күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез мөлкәт объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматларны үз эченә алган);<br>2) Россия Федерациясенең бюджет законнары белән билгеләнгән очракларда дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), атом энергиясе буенча "Росатом" Дәүләт корпорациясе, космик эшчәнлек буенча "Роскосмос" Дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджеттан тыш фонд идарәсе органы яки җирле үзидарә органы тарафыннан дәүләт (үзидарәлек) заказ бирүчесе вәкаләтләрен тапшыру турында бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда төзелгән килешү;<br>3)Җир кишәрлегенең төзелешкә рөхсәтнамә алуга гариза тапшыру көненә кадәр өч ел алдан бирелгән шәһәр төзелеше планы яисә линияле объектны төзүгә рөхсәтнамә бирелү очрагында территорияне планлаштыру һәм территорияне ызанлау проектлары реквизитлары;<br>4) Рөхсәт ителгән төзелеш, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәтнамә (РФ ШтК ның 40 маддәсе нигезендә андый рөхсәтнамә төзүчегә бирелү очрагында);<br>5)Тәңгәллек сертификатларының бердәм реестрыннан мәгълүматлар;<br>6) Проект документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе;<br>7) Проект документациясендәге материаллар.<br>Төзелешкә рөхсәтнамәгә үзгәрешләр кертү очрагында (кертелә торган үзгәрешләргә бәйле рәвештә):<br>1) Күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез мөлкәт объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматлары булган); | РФ ШтК ның 51 маддәсенең 7.1, 7.2, 9.1, 9.2, 21.12, 21.13 өлешләре |

| | | |
|---|---|---|
| | 2) РФ ШтК ның 51 маддәсенең 21.6 һәм 21.7 өлешләрендә каралган очракларда җир кишәрлекләрен оештыру турында карарны, әгәр җир законнары нигезендә җир кишәрлеген булдыру карарын дәүләт хакимиятенең башкарма органы яки җирле үзидарә органы кабул итсә;<br>3) Бүлгәндә, кабаттан бүлгәндә, аерганда барлыкка килгән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы;<br>4) РФ ШтК ның 51 маддәсенең 21.9 өлешендә күздә тотылган очракта җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензияне кабаттан рәсмиләштерү хакында карар;<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында тәгаенләнгән.<br>Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы югарыда санап кителгән документларны таләп итү тыела.<br>Югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны гариза бирүче тарафыннан тапшырмау гариза бирүчегә хезмәт күрсәтмәүгә нигез булып тора алмый. | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда күздә тотылган очракларда килештерүләре муниципаль хезмәт күрсәтү өчен таләп ителә һәм мондый ярәштыру муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнарының (җирле үзидарә органнарының) һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | Килештерү таләп ителми. | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен | 1) Документларны тиеш булмаган кеше тарафыннан | |

| | | |
|---|---|---|
| зарури документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | тапшыру;<br>2)Тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>3)Гаризада һәм гаризага теркәлгән документларда эчтәлекләрен бер мәгънәдә аңлатырга мөмкинлек бирмәүче искәртелмәгән төзәтүләр, җитди бозылулар булу;<br>4)Документларны тиеш булмаган органга тапшыру. | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр күздә тотылмый.<br>Төзелешкә рөхсәтнамә биргәндә кире кагу өчен нигезләр:<br>1) Гариза бирүче тарафыннан документлар тулы булмаган күләмдә тапшырылган яисә тапшырылган гаризада һәм (яки) документларда тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат бар.<br>2) Документларның җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы таләпләренә, шулай ук рөхсәт ителгән төзелеш, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәтнамәдә тәгаенләнгән таләпләргә туры килмәве;<br>3) Дәүләт органыннан, җирле үзидарә органыннан яисә дәүләт органы, җирле үзидарә органы карамагындагы оешмадан ведомствоара запроска муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яки) мәгълүматның (әгәр тиңдәшле документ гариза бирүче тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылмаган булса) булмавын раслаучы җавапның килеп ирешүе;<br>4) Мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле дәүләт органыннан капиталь төзелеш объекты проект документациясе бүлегенең яки индивидуаль торак төзелеше объекты тышкы кыяфәте тасвирламасының федераль яки төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә урнашкан территориаль зонага карата шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының архитектура чишелешләренә куелган таләпләргә һәм тарихи җирлекне | |

| | | |
|---|---|---|
| | саклау предметына туры килмәве турында бәяләмәнең килеп ирешүе.<br>Төзелешкә рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогын озайту очрагында кире кагу өчен нигезләр:<br>1)Капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау гариза бирү срогы чыкканчы башланмаган (төзүченең гаризасы төзелешкә рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогы чыкканчыга кадәр алтмыш көннән алда бирелергә тиеш).<br>Төзелешкә рөхсәтнамәгә үзгәрешләр кертү очрагында кире кагуга нигезләр:<br>1) Җир кишәрлегенә хокукларның күчүе турындагы, җир кишәрлегенең барлыкка килүе хакындагы хәбәрнамәдә РФ ШтК ның 51 маддәсенең 21.10 өлеше 1-4 пунктларында тиндәшле рәвештә күздә тотылган документларның реквизитлары булмавы яисә җир кишәрлегенә РФ ШтК ның 21.13 өлешендә күрсәтелгән очракта хокук урнаштыручы документның булмавы;<br>2) Җир кишәрлегенә хокукларның күчүе турындагы, җир кишәрлегенең барлыкка килүе хакындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән мәгълүматларның дөрес түгеллеге;<br>3) Капиталь төзелеш объектын планлаштырылган урнаштыруның капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү таләпләренә, төзелешкә рөхсәтнамә алу өчен тапшырылган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планының бирү датасына тәгаенләнгән җир кишәрлеген рөхсәт ителгән файдалануга һәм (яки) Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә РФ ШтК ның 51 маддәсе 21.7 өлешендә каралган очрактагы чикләүләргә туры килмәве. | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алынучы дәүләт пошлинасы һәм бүтән түләүнең тәртибе, күләме һәм түләтү нигезе | Муниципаль хезмәт бушлай күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алынучы түләүнең тәртибе, күләме һәм түләтү нигезе, андый түләүнең күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь срогы | Муниципаль хезмәт алуга гариза тапшыру чират булганда – 15 минуттан артмый.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел. | |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны теркәү срогы, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергән мизгелдән соң бер көн эчендә.<br>Электрон рәвештә ял (бәйрәм) көнне кергән запрос ял (бәйрәм) көн артыннан килүче эш көнендә теркәлә | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, көтеп тору һәм гариза бирүчеләрне кабул итү урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларга инвалидлар өчен үтүне тәэмин итүгә, андый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бина һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларга муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз килү тәэмин ителә (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм алар эчендә күченү).<br>Муниципаль хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләргә уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып. | |
| 2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркем өчен мөмкинлеге һәм сыйфат күрсәткечләре,шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара элемтәсе саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәтне дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, дәүләти һәм | Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкинлеге (доступность) күрсәткечләре булып тора:<br>-Бүлек бүлмәсенең Ленин урамының 48 йортында урнашып җәмәгать транспорты үтәрлек зонада булуы;<br>-белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүне гамәлгә ашыра торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;<br>-мәгълүмат стендларында, “Интернет” челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында (http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru), | |

| | | |
|---|---|---|
| муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең ераклашкан эш урыннарында алу мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы хакында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникация технологияләрен кулланып | дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталында муниципаль хезмәт күрсәтүнең ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүматның булуы;<br>-инвалидларга бүтәннәр белән бер үк дәрәҗәдә хезмәтләр алырга комачаулаучы киртәләрне җиңәргә ярдәм итү;<br>-КФҮ аша муниципаль хезмәт турында консультация алу, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирү, муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу;<br>- мәгълүмат стендларында, муниципаль районның “Интернет” челтәрендәге http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталында муниципаль хезмәт күрсәтүнең ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүматның булуы;<br>-Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинет аша электрон рәвештә гариза бирү, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу мөмкинлеге.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән характерлана:<br>-гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү һәм бирүдә чиратларның;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозуның;<br>-муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьнең;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата нәзакәтсезлегенә, илтифатсызлыгына шикаятьнең.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм мөрәҗәгать | |

| | | |
|---|---|---|
| | итүченең бер мәртәбә үзара элемтәсе фаразлана. Элемтәнең дәвамлылыгы регламент белән тәгаенләнә.<br>Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ) муниципаль хезмәт күрсәткәндә консультацияне, документларны алу-бирүне КФҮ белгече гамәлгә ашыра.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүматны гариза бирүче http://www.uslugi.tatarstan.ru сайтында, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru), КФҮ тә алырга мөмкин. | |
| 2.16. Электрон рәвештә үзидарәлек хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләре | Электрон рәвештә үзидарәлек хезмәте алу тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү бүлмәсе аша яки Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аркылы алырга мөмкин.<br>Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аркылы алынган гаризаны теркәү “Татарстан Республикасы Дәүләт мәгълүмат үзәге” Мәгълүмат системасының эчке файдаланучылары өчен электрон рәвештә дәүләти, үзидарәлек һәм социаль мөһимлеге булган хезмәтләрне күрсәтү өчен модульдә гамәлгә ашырыла.<br>Гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аркылы биргәндә үзидарәлек хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат, шулай ук үзидарәлек хезмәте нәтиҗәсе хакында мәгълүмат гариза бирүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталындагы шәхси кабинетына электрон рәвештә юллана, гариза бирүченең башкаручы белән турыдан-туры үзара элемтәсе таләп ителми. | |

**3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләренең ераклашкан эш урыннарында үтәү үзенчәлекләре**

3.1. Муниципаль хезмәтләр күрсәткәндәге гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1.Үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запросларны формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

3.2. Гариза бирүче белән консультацияләр үткәрү

3.2.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт алу тәртибе турында консультация алу өчен Бүлеккә шәхсән, телефон буенча һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хаклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка сораулар буенча һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутыруда булышлык күрсәтә.

Әлеге пунктта тәгаенләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, рәвеше һәм рөхсәт алуның башка сораулары буенча консультацияләр.

**Төзелешкә рөхсәтнамә бирү**

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән, ышанычлы зат аркылы яки КФҮ, КФҮ нең ераклашкан эш урыны аша үзидарәлек хезмәте күрсәтү турында язма рәвештә гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә Бүлеккә документларын тапшыра.

Үзидарәлек хезмәте күрсәтү турында электрон рәвештәге гариза Бүлеккә электрон почта буенча яки Интернет-кабул итү бүлмәсе аша җибәрелә. Электрон рәвештә кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.3.2. Бүлекнең гаризаларны кабул итүне алып баручы белгече гамәлгә ашыра:

гариза бирүченең шәхесен ачыклауны;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерүне (ышанычнамә буенча эш иткән очракта);

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күздә тотылган документларның булуын тикшерүне;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен (документлар күчермәләренең тиешенчә рәсмиләштерелүе, документларда кырып төзәтүләрнең, өстәп язуларның, сызылган сүзләрнең һәм искәртелмәгән бүтән төзәтүләрнең булмавын) тикшерүне.

Замечаниеләр булмаган очракта Бүлек белгече гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итүне һәм аны махсус журналда теркәүне;

гариза бирүчегә тәкъдим ителгән документларны алу турында документларны кабул итү датасы турында билге куеп, бирелгән керү номеры белән, муниципаль хезмәтне үтәүнең датасын һәм вакытын күрсәтеп опись күчермәсен тапшыруны;

гаризаны карау өчен Башкарма комитет җитәкчесенә җибәрүне.

Документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләр булган очракта Бүлекнең документлар кабул итүне алып баручы белгече гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуы турында гариза бирүчегә хәбәр итә һәм, документларны кабул итүне кире кагу өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язма рәвештә аңлатып, документларны аңа кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гамәлгә ашырыла:

15 минут эчендә гаризаны һәм документларны кабул итү;

гариза кергән мизгелдән соң бер көн эчендә гаризаны теркәү.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлеп Башкарма комитет җитәкчесе каравына җибәрелгән гариза яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Башкарма комитет җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны тәгаенли һәм гаризаны Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пунктча белән билгеләнгән процедура гариза теркәлгән мизгелдән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: башкаручыга юлланган гариза.

3.4. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү

3.4.1. Бүлек белгече ведомствоара электрон бәйләнеш (хезмәттәшлек) системасы ярдәмендә электрон рәвештә түбәндәгеләрне бирү турында запрос җибәрә:

1) Күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез мөлкәт объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматларны үз эченә алган);

2) Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы;

3) Рөхсәт ителгән төзелеш, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәтнамә (РФ ШтК ның 40 маддәсе нигезендә андый рөхсәтнамә төзүчегә бирелү очрагында);

4) Тәңгәллек сертификатларының бердәм реестрыннан мәгълүматлар;

5) Проект документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе;

Индивидуаль торак төзелеше объектына рөхсәтнамә бирү очрагында:

1) Күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез мөлкәт объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматларны үз эченә алган);

2) Җир кишәрлегенең төзелешкә рөхсәтнамә алуга гариза тапшыру көненә кадәр өч ел алдан бирелгән шәһәр төзелеше планы.

Әлеге пунктча белән билгеләнгән процедуралар үзидарәлек хезмәте күрсәтү турында гариза кергән мизгелдән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырылалар.

Процедураларның нәтиҗәсе: хакимият органнарына юлланган запрослар.

3.4.2. Ведомствоара электрон үзара бәйләнеш системасы (ВЭБС) аша кергән запрос нигезендә мәгълүмат тапшыручыларның белгечләре соратылган документларны (мәгълүматны) бирәләр яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен зарури документның һәм (яки) мәгълүматның булмавы хакында хәбәрнамә җибәрәләр (алга таба – кире кагу турында хәбәрнамә).

Әлеге пунктча белән тәгаенләнгән процедура документларны (мәгълүматларны) бирү турында запрос килеп ирешкән мизгелдән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яисә кире кагу турында хәбәрнамә.

3.5. Үзидарәлек хезмәте нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Бүлек белгече алынган документлар нигезендә:

рөхсәтнамәне бирү турында яки рөхсәтнамәне бирүне кире кагу хакында карар кабул итә;

рөхсәтнамә проектын яки кире кагуның сәбәпләрен күрсәтеп рөхсәтнамә бирүне кире кагу турында хат проектын әзерли;

рөхсәтнамә проектын (рөхсәтнамә бирү турында карар кабул ителү очрагында) яки рөхсәтнамә бирүне кире кагу турында хат проектын (рөхсәтнамә бирүне кире кагу турында карар кабул ителү очрагында) рәсмиләштерә;

билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән документ проектын яраштыру (килештерү) процедураларын гамәлгә ашыра;

документ проектын имза салуга Башкарма комитет җитәкчесенә (аның тарафыннан вәкаләтләр бирелгән затка) юллый.

Процедураларның нәтиҗәсе: кул куюга Башкарма комитет җитәкчесенә (аның тарафыннан вәкаләтләр бирелгән затка) юлланган документ проекты.

3.5.2. Башкарма комитет җитәкчесе (аның тарафыннан вәкаләтләр бирелгән зат) рөхсәтнамәне раслый, кул куя, Башкарма комитет мөһерен баса яисә рөхсәтнамә бирүне кире кагу турында хатны имзалый. Имза салынган документлар Бүлек белгеченә юллана.

3.5.1- 3.5.2 пунктчалары белән тәгаенләнгән процедуралар запросларга җаваплар килеп ирешкән мизгелдән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырылалар.

Процедураның нәтиҗәсе: кул куелган рөхсәтнамә яки рөхсәтнамә бирүне кире кагу турында хат.

3.6. Гариза бирүчегә үзидарәлек хезмәте нәтиҗәсен бирү

3.6.1. Бүлек белгече:

рөхсәтнамә бирү турындагы карарны (рөхсәтнамә бирүне кире кагу турында карарны) теркәү журналында терки;

гариза бирүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын файдаланып үзидарәлек хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәрнамә җиткерә, рәсмиләштерелгән рөхсәтнамәне яисә рөхсәтнамә бирүне кире кагу турында хатны кулга бирүнең датасын һәм вакытын хәбәр итә.

Әлеге пунктча белән тәгаенләнгән процедуралар документларга Башкарма комитет җитәкчесе кул куйган көнне гамәлгә ашырылалар.

Процедураларның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (аның вәкиленә) үзидарәлек хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәрнамә җиткерү.

3.6.2. Бүлек белгече гариза бирүчегә (аның вәкиленә) рәсмиләштерелгән рөхсәтнамәне бирелгән рөхсәтнамәләр журналында кул куйдырып тапшыра яки рөхсәтнамә бирүне кире кагу турында хатны кире кагуның сәбәпләрен күрсәтеп кулга бирә.

Әлеге пункт белән тәгаенләнгән процедуралар гамәлгә ашырылалар:

рөхсәтнамәне яки кире кагу турында хатны бирү – гариза бирүче килгән көнне чират тәртибендә 15 минут эчендә;

кире кагу турында хатны почта аркылы хат белән юллау – шушы Регламентның 3.5.2. пунктчасында каралган процедура төгәлләнгән мизгелдән соң бер көн эчендә;

Процедураларның нәтиҗәсе: кулга бирелгән рөхсәтнамә яки рөхсәтнамә бирүне кире кагу турында хат.

**3.7. Төзелешкә рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогын озайту**

3.7.1. Гариза бирүче шәхсән, ышанычлы зат аркылы яки КФҮ аша үзидарәлек хезмәте күрсәтү турында язма рәвештә гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә Бүлеккә документларын тапшыра. Документлар ераклашкан эш урыны аша да тапшырылырга мөмкин. Ераклашкан эш урыннарының исемлеге 4 номерлы кушымтада китерелгән.

Үзидарәлек хезмәте күрсәтү турында электрон рәвештәге гариза Бүлеккә электрон почта буенча яки Интернет-кабул итү бүлмәсе аша җибәрелә. Электрон рәвештә кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.7.2. Бүлекнең гаризаларны кабул итүне алып баручы белгече шушы Регламентның 3.2.2. пунктчасында күздә тотылган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктча белән билгеләнгән процедуралар гамәлгә ашырыла:

15 минут эчендә гаризаны һәм документларны кабул итү;

гариза кергән мизгелдән соң бер көн эчендә гаризаны теркәү.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлеп Башкарма комитет җитәкчесе каравына җибәрелгән гариза яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.7.3. Башкарма комитет җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны тәгаенли һәм гаризаны Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пунктча белән билгеләнгән процедура гариза теркәлгән мизгелдән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: башкаручыга юлланган гариза.

3.7.4. Бүлек белгече алынган документлар нигезендә:

рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогын озайту турында яки рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогын озайтуны кире кагу хакында карар кабул итә;

рөхсәтнамә бланкына зарури үзгәрешләрне кертә яки рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогын озайтуны кире кагу турында, сәбәпләрен күрсәтеп, хат проекты әзерли;

билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән документ проектын килештерү процедураларын гамәлгә ашыра;

документ проектын имза салуга Башкарма комитет җитәкчесенә (аның тарафыннан вәкаләтләр бирелгән затка) юллый.

Әлеге пунктча белән тәгаенләнгән процедура документлар килеп ирешкән мизгелдән соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Башкарма комитет җитәкчесенә (аның тарафыннан вәкаләтләр бирелгән затка) имза салуга юлланган документ проекты.

3.7.5. Башкарма комитет җитәкчесе (аның тарафыннан вәкаләтләр бирелгән зат) рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогын озайтуны раслый, кул куя, Башкарма комитет мөһерен баса яисә рөхсәтнамәнең срогын озайтуны кире кагу турында хатны имзалый. Имза салынган документлар Бүлек белгеченә юллана.

Әлеге пунктча белән тәгаенләнгән процедура документлар килеп ирешкән мизгелдән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кул куелган срогы озайтылган рөхсәтнамә яки рөхсәтнамәнең срогын озайтуны кире кагу турында хат.

3.7.6. Гариза бирүчегә үзидарәлек хезмәте нәтиҗәсен бирү

Гариза бирүчегә үзидарәлек хезмәте нәтиҗәсен бирү әлеге Регламентның 3.6.1-3.6.2 пунктчалары нигезендә гамәлгә ашырыла.

**3.8. Төзелешкә рөхсәтнамәгә үзгәрешләр кертү**

3.8.1. Гариза бирүче шәхсән, ышанычлы зат аркылы яки КФҮ аша җир кишәрлекләренә хокукларның, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукының күчүе, җир кишәрлеге барлыкка килү турында хәбәрнамә ирештерә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә Бүлеккә документларын тапшыра. Документлар ераклашкан эш урыны аша да тапшырылырга мөмкин. Ераклашкан эш урыннарының исемлеге 4 номерлы кушымтада китерелгән.

Хәбәрнамә электрон рәвештә Бүлеккә электрон почта буенча яки Интернет-кабул итү бүлмәсе аша җибәрелә. Электрон рәвештә кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.8.2. Бүлекнең гаризаларны кабул итүне алып баручы белгече шушы Регламентның 3.2.2. пунктчасында күздә тотылган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктча белән билгеләнгән процедуралар гамәлгә ашырыла:

15 минут эчендә гаризаны һәм документларны кабул итү;

гариза кергән мизгелдән соң бер көн эчендә гаризаны теркәү.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлеп Башкарма комитет җитәкчесе каравына җибәрелгән гариза яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.8.3. Башкарма комитет җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны тәгаенли һәм гаризаны Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пунктча белән билгеләнгән процедура гариза теркәлгән мизгелдән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: башкаручыга юлланган гариза.

3.8.4. Бүлек белгече документларны тикшерә һәм зарурлык туганда электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәгеләрне җибәрү турында запрослар юллый:

1) шушы маддәнең 21.5 өлешендә күрсәтелгән очракларда андый җир кишәрлекләренә хокук урнаштыручы документларны;

2) шушы маддәсенең 21.6 һәм 21.7 өлешләрендә каралган очракларда җир кишәрлекләрен оештыру турында карарны, әгәр җир законнары нигезендә җир кишәрлеген булдыру карарын дәүләт хакимиятенең башкарма органы яки җирле үзидарә органы кабул итсә;

3) шушы маддәсенең 21.7 өлешендә күздә тотылган очракта капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләүне гамәлгә ашыру планлаштырыла торган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын;

4) шушы маддәсенең 21.9 өлешендә күздә тотылган очракта җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын бирү турындагы һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензияне яңадан рәсмиләштерү хакындагы карарны.

Әлеге пунктча белән билгеләнгән процедуралар үзидарәлек хезмәте күрсәтү турында гариза килеп ирешкән мизгелдән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: хакимият органнарына юлланган запрослар.

3.8.5. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрос нигезендә мәгълүмат тапшыручыларның белгечләре соратылган документларны (мәгълүматны) бирәләр яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен зарури документның һәм (яки) мәгълүматның булмавы хакында хәбәрнамә җибәрәләр (алга таба – кире кагу турында хәбәрнамә).

Әлеге пунктча белән тәгаенләнгән процедуралар документларны (мәгълүматларны) бирү турында запрос килеп ирешкән мизгелдән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яисә кире кагу турында хәбәрнамә.

3.8.6. Бүлек белгече алынган документлар нигезендә:

төзелешкә рөхсәтнамәгә үзгәрешләр кертү турында яки кире кагу хакында карар кабул итә;

рөхсәтнамә бланкына зарури үзгәрешләрне кертә яки рөхсәтнамәне үзгәртүне кире кагу турында, сәбәпләрен күрсәтеп, хат проекты әзерли;

билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән документ проектын килештерү процедураларын гамәлгә ашыра;

документ проектын имза салуга Башкарма комитет җитәкчесенә (аның тарафыннан вәкаләтләр бирелгән затка) юллый.

Процедураларның нәтиҗәсе: кул куюга Башкарма комитет җитәкчесенә (аның тарафыннан вәкаләтләр бирелгән затка) юлланган документ проекты.

3.8.7. Башкарма комитет җитәкчесе (аның тарафыннан вәкаләтләр бирелгән зат) үзгәрешләрне раслый, кире кагу турындагы хатны имзалый. Имза салынган документлар Бүлек белгеченә юллана.

3.8.6 - 3.8.7 пунктчалары белән тәгаенләнгән процедуралар запросларга җаваплар килеп ирешкән мизгелдән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кул куелган рөхсәтнамә яки кире кагу турында хат.

3.8.8.Гариза бирүчегә үзидарәлек хезмәте нәтиҗәсен бирү

Гариза бирүчегә үзидарәлек хезмәте нәтиҗәсен бирү шушы Регламентның 3.6.1-3.6.2 пунктчаларына ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

**3.9. Төзелешкә рөхсәтнамәнең дубликатын бирү**

3.9.1. Төзелешкә рөхсәтнамәне югалту (бозу) очрагында гариза бирүче Бүлеккә рөхсәтнмәнең дубликатын бирү турында гариза тапшыра.

Гариза гариза бирүче (вәкаләтле зат) тарафыннан шәхсән яисә почта аркылы (шул исәптән электрон почтаны файдаланып) яки дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләренең бердәм порталы яисә дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша бирелә.

3.9.2. Бүлекнең гаризаларны кабул итүне алып баручы белгече дубликат бирү турындагы гаризаны кабул итүне гамәлгә ашыра, теркәлгән документлары белән бергә гаризаны терки һәм аларны Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктча белән тәгаенләнгән процедура гариза теркәлгән мизгелдән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгече каравына юлланган кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.9.3. Бүлек белгече документларны карый һәм нигезләр булганда җирле үзидарә органы архивындагы икенче нөсхәсе нигезендә төзелешкә рөхсәтнамәнең дубликатын әзерли. Төзелешкә

рөхсәтнамә дубликатының тышкы ягының уңъяк өске почмагына "Дубликат" дигән штамп куела. Кире кагу очрагында кире кагу турында хат проектын әзерли. Билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән документ проектын килештерә.

Гариза бирүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын файдаланып үзидарәлек хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәрнамә җиткерә, рәсмиләштерелгән рөхсәтнамәне яисә рөхсәтнамә бирүне кире кагу турында хатны кулга бирүнең датасын һәм вакытын хәбәр итә.

Әлеге пунктча белән тәгаенләнгән процедуралар документларга Башкарма комитет җитәкчесе кул куйган көнне гамәлгә ашырылалар.

Процедураларның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (аның вәкиленә) үзидарәлек хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәрнамә җиткерү.

3.9.4. Бүлек белгече гариза бирүчегә (аның вәкиленә) рәсмиләштерелгән рөхсәтнамәне бирелгән рөхсәтнамәләр журналында кул куйдырып тапшыра яки рөхсәтнамә бирүне кире кагу турында хатны кире кагуның сәбәпләрен күрсәтеп кулга бирә.

Әлеге пункт белән тәгаенләнгән процедуралар гамәлгә ашырылалар:

рөхсәтнамәне яки кире кагу турында хатны бирү – гариза бирүче килгән көнне чират тәртибендә 15 минут эчендә;

кире кагу турында хатны почта аркылы хат белән юллау – шушы Регламентның 3.9.3. пунктчасында каралган процедура төгәлләнгән мизгелдән соң бер көн эчендә;

Процедураларның нәтиҗәсе: кулга бирелгән рөхсәтнамә яки рөхсәтнамә бирүне кире кагу турында хат.

3.10**. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү.**

3.10.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт алу өчен КФҮ кә, КФҮ нең ераклашкан эш урынына мөрәҗәгать итәргә хаклы.

3.10.2. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү КФҮ нең билгеләнгән тәртиптә расланган эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.10.3. Муниципаль хезмәт алуга КФҮ тән документлар килеп ирешкәндә процедуралар әлеге Регламентның 3.3 – 3.5 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәтнең нәтиҗәсе КФҮ кә җибәрелә.

3.11.**Техник хаталарны төзәтү**.

3.11.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документта техник хата барлыгы беленгән очракта гариза бирүче Бүлеккә тәкъдим итә:

-техник хатаны төзәтү турында гариза (кушымта №3);

-муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак гариза бирүчегә бирелгән техник хаталы документ;

-техник хата булуны дәлилләүче юридик көчкә ия булган документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документта күрсәтелгән мәгълүматлардагы техник хатаны төзәтү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән яисә почта аша тапшырыла (шул исәптән электрон почтаны файдаланып), яки дәүләт һәм муниципаль (үзидарәлек) хезмәтләрнең Бердәм порталы яисә дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең күпфункцияле үзәге аша.

3.11.2. Документлар кабул итүгә җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, теркәлгән документлары белән гаризаны терки һәм Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пункт белән тәгаенләнгән процедура гаризаны теркәгән мизгелдән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Бүлек белгеченә карауга җибәрелгән гариза.

3.11.3. Бүлек белгече документларны карый һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка төзәтүләр кертү максатларында әлеге Регламентның 3.5 пунктында күздә тотылган процедураларны гамәлгә ашыра һәм төзәтелгән документны гариза бирүчегә (вәкаләтле

вәкилгә) шәхсән кул куйдырып тапшыра. Шуның белән бергә гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хата булган документның оригиналын (төп нөсхәсен) ала яки почта аша (электрон почта ярдәмендә) гариза бирүчегә техник хаталы документның оригиналын Бүлеккә тапшырганда документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән тәгаенләнгән процедура техник хата беленгәннән соң яки җибәрелгән хата турында теләсә кайсы кызыксынучы заттан гариза кергәннән соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган (юлланган) документ.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә контроль тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына контроль гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылуын ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлүенә тикшерүләр уздыруны, җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешенә контроль формалары булып торалар:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектка виза салу тора;

2) билгеләнгән тәртиптә уздырылучы делопроизводствоны алып баруны тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларын үтәүгә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарәнең ярты еллык һәм еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырылырга тиешле) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләрне үткәргәндә муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле бөтен сораулар да (комплекслы тикшерү) яисә гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча сорау каралырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр кылуга контрольне гамәлгә ашыру максатларында һәм карарлар кабул иткәндә Башкарма комитет җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тәкъдим ителә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедуралар белән тәгаенләнгән гамәлләр эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контроль Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыруга җаваплы кеше, шулай ук инфраструктура үсеше бүлеге белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның исемлеге җирле үзидарә органының структура бүлекчәләре турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән тәгаенләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр йомгаклары буенча гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылулар беленгән очракта гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җавапка тартылалар.

4.4. Гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен үзвакытында карамаган өчен җирле үзидарә органы җитәкчесе җаваплы була.

Җирле үзидарә органының структура бүлекчәсе җитәкчесе (урынбасары) әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне үзвакытында һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы була.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен вазыйфаи затлар һәм бүтән үзидарәлек хезмәткәрләре Закон тәртибендә билгеләнгән җаваплылыкны тота.

4.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контроль муниципаль хезмәт күрсәткәндә Башкарма комитет эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка чаклы карау мөмкинлеге булу аркасында гамәлгә ашырыла.

**5. Муниципаль хезмәт күрсәтү органнарының, шулай ук аларның урындагы затларының, үзидарәлек хезмәткәрләренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук дәүләт яки үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү буенча функцияләрне гамәлгә ашыручы оешмаларның яисә аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе**

5.1. Муниципаль хезмәтне алучы Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәрге тәртиптә Башкарма комитетка шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросның, 27.07.2010 № 210-ФЗ Федераль законның 15.1 маддәсендә күрсәтелгән запросның теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге (судтан тыш) шикаять бирү шул очракта мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тиңдәшле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән тәгаенләнгән тәртиптә тулы күләмдә йөкләнгән булса;

3). гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы норматив хокукый актлары тарафыннан тәкъдим итү яисә гамәлгә ашыру каралмаган документлар яки мәгълүматларны яисә гамәлләр кылуны таләп итү;

4). гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы норматив хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүне кире кагу;

5) федераль законнар һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары, Балык Бистәсе муниципаль районы норматив хокукый актларында кире кагуга нигезләр күздә тотылмаган булуга карамастан, муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу; Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге (судтан тыш) шикаять бирү шул очракта мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тиңдәшле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән тәгаенләнгән тәртиптә тулы күләмдә йөкләнгән булса;

6). муниципаль хезмәт күрсәтүдә гариза бирүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы норматив хокукый актларында күздә тотылмаган түләүне таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның урындагы затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы алар тарафыннан җибәрелгән хата һәм ялгышларны төзәтүне кире кагуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу; Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге (судтан тыш) шикаять бирү шул очракта мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тиңдәшле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән тәгаенләнгән тәртиптә тулы күләмдә йөкләнгән булса;

8). муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирүнең срогын яисә тәртибен бозу;

9). федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары, муниципаль районның норматив хокукый актларында муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатуга нигезләр күздә тотылмаган булуга карамастан, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату (туктатып тору); Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге (судтан тыш) шикаять бирү шул очракта мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тиңдәшле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән тәгаенләнгән тәртиптә тулы күләмдә йөкләнгән булса;

10). муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны баштагы кабул итүдәге кире кагуда юклыгы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә, 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 7 маддәсе 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан гайре, гариза бирүчедән таләп итү.

5.2.Шикаять кәгазь йөрткечтә язма рәвештә, электрон рәвештә Башкарма комитетка, күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкнең оештыручысы булып торган (алга таба – күпфункцияле үзәкнең оештыручысы) ачык-хокукый берәмлек дәүләт хакимиятенең тиешле органына (җирле үзидарә органына), шулай ук 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралган оешмаларга бирелә. Башкарма комитет җитәкчесе карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять югарыгы органга (ул булган сурәттә) бирелә яисә ул булмаганда турыдан-туры Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан карала. Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять әлеге күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә. Күпфункцияле үзәк карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәкне оештыручыга яки Татарстан Республикасы норматив хокукый акты белән вәкаләт бирелгән урындагы затка бирелә. 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр бу оешмаларның җитәкчеләренә бирелә.

Башкарма комитетның, Башкарма комитетның урындагы затының, үзидарәлек хезмәткәренең, үзидарәлек хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенең карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта белән, күпфункцияле үзәк аша “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтын (www.ribnaya-sloboda.tatarstan.ru), дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләренең (функцияләренең) Бердәм порталын (http://www.gosuslugi.ru/), Татарстан Республикасының дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләренең Бердәм порталын (http://uslugi.tatar.ru/) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итүдә кабул ителергә мөмкин.

Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта белән, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтын, дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләренең (функцияләренең) Бердәм порталын (http://www.gosuslugi.ru/), Татарстан Республикасының дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләренең Бердәм порталын (http://uslugi.tatar.ru/) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итүдә кабул ителергә мөмкин. 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта белән, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, бу оешмаларның рәсми сайтларын, дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләренең (функцияләренең) Бердәм порталын (http://www.gosuslugi.ru/), Татарстан Республикасының дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләренең Бердәм порталын (http://uslugi.tatar.ru/) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итүдә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Башкарма комитетка, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең оештыручысына, 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югарыгы органга (ул булган сурәттә) килеп ирешкән шикаять аның теркәлгән көненнән соң унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш, ә Башкарма комитетның, күпфункцияле үзәкнең,

27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралган оешмаларның гариза бирүчедән документларны кабул итүне кире кагуына шикаять яисә җибәрелгән хата һәм ялгышларны төзәтүне яки андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга шикаять – аның теркәлгән көненнән соң биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган хезмәт күрсәтүче органның, органның урындагы затының яки үзидарәлек хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең, 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) хезмәткәрләренең исемен;

2) гариза бирүченең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булганда), тору урыны турында мәгълүматларны – физик затның яисә гариза бирүченең исеме, урнашу урыны турында мәгълүматларны – юридик затның, шулай ук гариза бирүчегә җавап җибәрү өчен контакт телефоны номерын (номерларын), электрон почта адресын (адресларын) (булганда) һәм почта адресын;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең шикаять бирелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматларны;

4) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән гариза бирүченең риза булмавына нигез булып торган дәлилләрне.

5.5. Шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре шикаятькә теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документларның исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның кайсы да булса берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хата һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, үзидарәлек хокукый актларында түләтү күздә тотылмаган акча средстволарын гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүне кире кагу.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көн артыннан килүче көннән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә язма рәвештә һәм аның теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилле җавап җибәрелә.

5.7. Шикаятьнең канәгатьләндерелергә тиешле дип табылу очрагында гариза бирүчегә җавапта муниципаль хезмәт күрсәткәндә беленгән бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында Башкарма комитет тарафыннан тормышка ашырылучы гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук күрсәтелгән уңайсызлыклар өчен кичерү сорала һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне алу максатларында гариза бирүчегә кылу зарур булган алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаятьнең канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип табылу очрагында гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре хакында дәлилле аңлатмалар бирелә, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат китерелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре табылу очрагында шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрәләр.

Капиталь төзелеш объектларын
төзүгә, реконструкцияләүгә
рөхсәтнамә бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтү
Административ регламентына
кушымта №1

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе

____________________________________
(Ф.И.А.и.)
__________________________________
____________________________________
____________________________________
(физик зат өчен: гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм (булса) атасының исеме, гариза бирүченең яшәү урыны, гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документының реквизитлары;
юридик зат өчен: гариза бирүченең исеме һәм урнашу урыны, юридик затларның бердәм дәүләт реестрында юридик затның дәүләт теркәве турында язмасының дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең таныклау номеры, гариза бирүче булып чит ил юридик заты торган очрактан гайре)

__________________________________
(гариза бирүче белән элемтә өчен почта һәм (яки) электрон почта адресы)

## Төзелешкә рөхсәтнамә бирү турында гариза

____________________________________________________________адресы буенча
(шәһәр, район, урам, кишәрлекнең номеры)
урнашкан җир кишәрлегендә ________________________________________________________
(объектның исеме)
төзүгә / реконструкцияләүгә _______ай срокка рөхсәтнамә бирүегезне үтенәм.
(кирәклесенең астына сызарга)

___________________________
Төзү (реконструкцияләү)
“ _____” ___________ел № ___ __________________________________________нигезендә
(документның исеме)
гамәлгә ашырылачак.
Җирдән файдалану хокукы беркетелгән_____________________________________________
( документның исеме)
________________________________________ “_____” ______________ел № ______________

Объект төзелешенә проект документациясе эшләнде ______________________________
________________________________________________________________________________
(проект оешмасының исеме, ИНН, юридик һәм почта адреслары,
________________________________________________________________________________
җитәкчесенең Ф.И.А.и. , телефон номеры, банк реквизитлары
________________________________________________________________________тарафыннан,
(банк исеме, р/с, к/с, БИК))

проект эшләрен үтәүгә хокуклы, беркетелгән ____________________________________

_______________________________________________________________________

(документның һәм аны биргән вәкаләтле оешманың исеме)

“_____” _________________ ел № _________________ һәм билгеләнгән тәртиптә кызыксынучы оешмалар, архитектура һәм шәһәр төзелеше органнары белән килештерелгән:

– дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе алынды № _________ _________________
“_____” _________________ ел

– планлаштыручы оешманың җир кишәрлеге схемасы килештерелде: _________________

_________________________________________ № ____________ “_____” ____________ ел

(оешманың исеме)

Проект-смета документациясе расланды: ___________________________________

_________________________________________ № ____________ “_____” ______________ ел

Өстәмә хәбәр итәбез:

Төзүче тарафыннан төзелешне (реконструкция, капиталь ремонт) финанслау гамәлгә ашырылачак _______________________________________________________________

(банк реквизитлары һәм счет номеры)

Эшләр подряд (хуҗалык) ысулы белән шартнамә нигезендә башарылачак: “_____” _________________ 20_____ ел № ________________________________

_______________________________________________________________________

(оешманың исеме, ИНН,

_______________________________________________________________________

юридик һәм почта адреслары, җитәкчесенең Ф.И.А.и. , телефон номеры,

_______________________________________________________________________

банк реквизитлары (банкның исеме, р/с, к/с, БИК))

Төзү-монтажлау эшләрен башкару хокукы беркетелгән: _______________________

_______________________________________________________________________

(документның һәм аны биргән вәкаләтле оешманың исеме)

_______________________________________________________________________

“_____” _________________ ел № _______________________

Эшләрне башкаручы итеп __________ “ _____” ______________ ел № ____________ боерык белән билгеләнде: _________________________________________________

(вазифасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_________________махсус белемле һәм төзелештә_______ел эш стажы бар.

(югары, урта) _________________________________________________________

_______________________

Төзелеш контроле “ ____” __________ ел № __________ шартнамәсе нигезендә гамәлгә ашырылачак:

_______________________________________________________________________

(оешманың исеме, ИНН, юридик һәм

_______________________________________________________________________

почта адреслары, җитәкчесенең Ф.И.А.и. , телефон номеры, банк

_______________________________________________________________________

реквизитлары (банкның исеме, р/с, к/с, БИК))

заказ бирүче (төзүче) функцияләрен башкару хокукы беркетелгән: _______________

_______________________________________________________________________

(документның һәм аны биргән оешманың исеме)

№ ____________ “_____” ______________________ ел

Гаризага сканерланган түбәндәге документлар теркәлә:

1) Җир кишәрлегенә хокук урнаштыручы документлар, әгәр аңа хокук күчемсез мөлкәткә һәм аның белән килешүләргә хокукларның Бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса;

2) Проект документациясендәге материаллар:

а) аңлатма язуы;

б) планлаштыручы оешманың җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы нигезендә башкарылган капиталь төзелеш объектының урнашу урынын, аңа килү һәм үтү юлларын, ачык сервитут тәэсире (көче) зоналары, археологик мирас объектлары чикләрен билгеләп җир кишәрлеге схемасы;

в) планлаштыручы оешманың территорияне планлаштыру буенча документациясе составында расланган линияле объектларга карата кулланылучы кызыл линияләр чикләрендә линияле объектның урнашуын раслаучы җир кишәрлеге схемасы;

г) архитектура чишелешләрен чагылдыручы схемалар;

д) инженерлык җиһазлары турында мәгълүматлар, проектланучы капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэминат челтәрләренә кушу (технологик тоташтыру) урыннарын билгеләп инженер-техник тәэминат челтәрләренең җыелма планы;

е) капиталь төзелеш объектын төзү оешмасы (төзүне оештыру) проекты;

ж) капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен җимерү яки сүтеп алу буенча эшләрне оештыру проекты;

3) капиталь төзелеш объектын реконструкцияләү очрагында объектның барлык хокукый ияләренең ризалыгы.

Индивидуаль торак төзелеше объектын төзү, реконструкцияләү очрагында:

1) җир кишәрлегенә хокук урнаштыручы документлар, әгәр күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки алардагы мәгълүматлар) күчемсез мөлкәткә һәм аның белән килешүләргә хокукларның Бердәм дәүләт реестрында булмаса;

2) планлаштыручы оешманың индивидуаль торак төзелеше объектының урнашу урының билгеләп җир кишәрлеге схемасы.

Төзелешкә рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогын озайту турында гариза торак урынын, гражданнарның һәм юридик затларның акча средстволарын күпфатирлы йортны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзүдә өлешләп катнашу өчен тапшыруны күздә тоткан шартнамә нигезендә төзелештә өлешләп катнашуга җәлеп итүче төзүче тарафыннан бирелгән очракта мондый гаризага төзүче тарафыннан төзелештә өлешләп катнашу шартнамәсе нигезендә торак урынны тапшыру буенча йөкләмәләрен тиешенчә үтәү өчен банкның поручительлек шартнамәсе яисә күпфатирлы йорт төзелешендә һәм (яки) (төзүченең) күчемсез милкенең бүтән объектларын төзүдә өлешләп катнашу өчен акча средстволарын җәлеп итүче затның гражданлык җаваплылыгын иминләштерү шартнамәсе теркәлергә тиеш.

Запрос булганда сканерланган документларның төп нөсхәләрен тапшыруны үз өстемә алам.

Шушы гаризада китерелгән мәгълүматлар белән бәйле барлык үзгәрешләр турында
_______________________________________________________________

(вәкаләтле органның исеме)
_______________________________________________________________

хәбәр итүне үз өстемә алам.

_______________________________________________________________

| | | |
|---|---|---|
| ____________________ | ____________________ | ____________________ |
| (вазифа) | (имза) | (Ф.И.А.и.) |

“_____” _________________ 20_____ ел

Капиталь төзелеш объектларын
төзүгә, реконструкцияләүгә
рөхсәтнамә бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтү
Административ регламентына
кушымта №2

## ТӨЗЕЛЕШКӘ РӨХСӘТНАМӘ ФОРМАСЫ

Кемгә ___________________________________
(төзүченең исеме
_________________________________________
(фамилиясе,исеме,атасының исеме-гражданнар өчен,
_________________________________________
Оешманың тулы исеме – юридик затлар
_________________________________________
өчен), аның почта индексы
_________________________________________
һәм адресы, электрон почта адресы) <1>

Төзелешкә
РӨХСӘТНАМӘ

Дата _________________ <2> № _________________ <3>

___________________________________________________________________________
(Төзелешкә рөхсәтнамә бирүне гамәлгә ашыручы башкарма хакимиятнең вәкаләтле Федераль органы яки Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органы
___________________________________________________________________________
яисә җирле үзидарә органы исеме. Атом энергиясе буенча "Росатом" дәүләт корпорациясе) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 маддәсе нигезендә рөхсәт бирә:

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Капиталь төзелеш объектын төзүгә <4> | |
| | Капиталь төзелеш объектын реконструкцияләүгә <4> | |
| | Мәдәни мирас объектын саклау буенча андый объектның конструкцияләре һәм ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгының бүтән сыйфатламаларына кагылган эшләр <4> | |
| | Линияле объект (линияле объект составына керүче капиталь төзелеш объекты) төзелеше <4> | |
| | Линияле объектны (линияле объект составына керүче капиталь төзелеш объектын) реконструкцияләү <4> | |
| 2. | Проект документациясе нигезендә капиталь төзелеш объекты (этабы) исеме <5> | |
| | Проект документациясенә уңай бәяләмә биргән оешманың исеме һәм Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда дәүләт | |

<table>
<tr><td rowspan="2"></td><td colspan="2">экология экспериzасына уңай бәяләмәне раслау турында боерык реквизитлары <5></td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td colspan="2">Проект документациясенә уңай бәяләмәне теркәү номеры һәм бирү датасы һәм Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда дәүләт экология экспериzасына уңай бәяләмәне раслау турында боерык реквизитлары <6></td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td rowspan="3">3.</td><td colspan="2">Чикләрендә капиталь төзелеш объекты урнашкан яки урнаштыру планлаштырыла торган җир кишәрлегенең (кишәрлекләренең) кадастр номеры <7></td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td colspan="2">Чикләрендә капиталь төзелеш объекты урнашкан яки урнаштыру планлаштырыла торган кадастр кварталы (кадастр кварталлары) номеры <7></td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td colspan="2">Реконструкцияләнә торган капиталь төзелеш объектының кадастр номеры <8></td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td>3.1.</td><td colspan="2">Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы турында мәгълүматлар <9></td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td>3.2.</td><td colspan="2">Планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты турында мәгълүматлар <10></td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td>3.3.</td><td colspan="2">Төзүгә, реконструкцияләүгә, объектның конструкцияләре һәм ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгының бүтән сыйфатламаларына кагылган мәдәни мирас объектын саклау эшләре үткәрүгә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектының проект документациясе турында мәгълүматлар <11></td><td colspan="2"></td></tr>
<tr><td rowspan="5">4.</td><td colspan="4">Капиталь төзелеш объектын, мәдәни мирас объектын төзү, реконструкцияләү өчен кыскача проект сыйфатламалары, әгәр мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр үткәргәндә объектның конструкцияләре һәм ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгының бүтән сыйфатламаларына кагылу булса <12></td></tr>
<tr><td colspan="4">Проект документациясе нигезендә мөлкәт комплексы составына керүче капиталь төзелеш объектының исеме: <13></td></tr>
<tr><td>Гомуми мәйдан (кв. м):</td><td></td><td>Кишәрлек мәйданы (кв. м):</td><td></td></tr>
<tr><td>Күләм (куб. м):</td><td></td><td>Шул исәптән җир асты өлешенең (куб.):</td><td></td></tr>
<tr><td>Катлар саны (шт.):</td><td></td><td>Биеклек (м):</td><td></td></tr>
</table>

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Жир астындагы катлар саны (данә): | | Сыешлык (кеше): | |
| | Корылма мәйданы (кв. м): | | | |
| | Бүтән күрсәткечләр <14>: | | | |
| 5. | Объектның адресы (урнашу урыны) <15>: | | | |
| 6. | Линияле объектның кыскача проект сыйфатламалары<16>: | | | |
| | Категория (класс): | | | |
| | Озынлык: | | | |
| | Егәрлек (үткәрү сәләте, йөк әйләнеше, хәрәкәт киеренкелеге): | | | |
| | Тип (КЛ, ВЛ, КВЛ), электр тапшыру линияләренең көчәнеш (йөкләнеш) дәрәҗәсе | | | |
| | Иминлеккә йогынты ясаучы конструкция элементларының исемлеге: | | | |
| | Башка күрсәткечләр <17>: | | | |

_____________________________________________________<18>нигезендә әлеге рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогы 20__елның __ _______________кадәр.

____________________________________ __________ _____________________

(төзелешкә рөхсәтнамә бирүне гамәлгә ашыручы оешманың вәкаләтле затының вазифасы) (имза) (имзаның расшифровкасы)

"__" _____________ 20__ ел

М.У.

Әлеге рөхсәтнамәнең гамәлдә булу вакыты 20___елның ____ ______________-на (-нә)кадәр озайтылды <19>

____________________________________ __________ _____________________

(төзелешкә рөхсәтнамә бирүне гамәлгә ашыручы оешманың (имза) (имзаның расшифровкасы)

вәкаләтле затының вазифасы)

"__" _____________ 20__ ел

М.У.

--------------------------------

<1> Күрсәтелә:

- төзелешкә рөхсәтнамә бирү өчен нигез булып физик затның гаризасы торганда гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган сурәттә);

- төзелешкә рөхсәтнамә бирү өчен нигез булып юридик затның гаризасы торганда Россия Федерациясе Граждан кодексының 54 маддәсе нигезендә оешманың тулы исеме (атамасы).

<2> Төзелешкә рөхсәтнамәгә кул кую датасы күрсәтелә.

<3> Төзелешкә рөхсәтнамә бирүне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан төзелешкә рөхсәтнамәнең А-Б-В-Г структуралы номеры күрсәтелә, биредә:

А – Россия Федерациясенең территориясендә капиталь төзелеш объектын төзү (реконструкцияләү) планлаштырыла торган субъекты номеры (икеурынлы).

Объектның Россия Федерациясенең ике һәм аннан күбрәк субъекты территориясендә урнашу очрагында "00" номеры күрсәтелә;

Б – территориясендә капиталь төзелеш объектын төзү (реконструкцияләү) планлаштырыла торган муниципаль берәмлеккә бирелгән теркәү номеры. Объектның ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлек территориясендә урнашу очрагында "000" номеры күрсәтелә;

В – төзелешкә рөхсәтнамә бирүне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан бирелгән төзелешкә рөхсәтнамәнең тәртип номеры;

Г – төзелешкә рөхсәтнамә бирелгән ел (тулысынча).

Номерның состав өлешләре бер-берсеннән "-" тамгасы белән аерыла. Цифрлы индекслар гарәп цифрлары белән тамгалана.

Башкарма хакимиятнең федераль органнары һәм Атом энергиясе буенча "Росатом" дәүләт корпорациясе өчен номер ахырында Атом энергиясе буенча "Росатом" дәүләт корпорациясенең үзләре тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тәгаенләнә торган органның шартлы тамгаланышы күрсәтелергә мөмкин.

<4> Төзелешкә рөхсәтнамә рәсмиләштерелә торган төзү (реконструкцияләүнең) санап кителгән төрләренең берсе күрсәтелә.

<5> Төзүче яки заказ бирүче тарафыннан расланган проект документациясе нигезендә капиталь төзелеш объектының исеме күрсәтелә.

<6> Атом энергиясен файдалану өлкәсендәге объектлар өчен төзелешкә рөхсәтнамә бирү очрагында шулай ук атом энергиясен файдалану өлкәсендә эшләр алып бару хокукына лицензиянең атом энергиясен файдалану объектын кору хокукын үз эченә алган мәгълүматлары да (номер, дата) күрсәтелә.

<7>Линияле объектны төзүгә (реконструкцияләүгә) рөхсәтнамә биргәндә тутыру мәҗбүри түгел.

<8> Объектның конструкцияләре һәм ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгының бүтән сыйфатламаларына кагылган мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр үткәрү очрагында күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастрында исәпкә алынган мәдәни мирас объектының кадастр номеры күрсәтелә.

<9> Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү датасы, аның номеры һәм җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирүче орган күрсәтелә (линияле объектларга карата тутырылмый, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан гайре).

<10> Линияле объектларга карата тутырыла, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан гайре. Планлаштыру проектын һәм территорияне ызанлау проектын раслау турында карарның (шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системаларында булган мәгълүматлар нигезендә) датасы һәм номеры һәм андый карарны кабул итүче зат (башкарма

хакимиятнең вәкаләтле федераль органы яки Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы яисә җирле хакимият башлыгы) күрсәтелә.

<11> Проект документациясенең кем тарафыннан, кайчан эшләнүе күрсәтелә (документның реквизитлары, проект оешмасының исеме).

<12>Линияле объектларга карата бүлекнең бар графаларын да тутырып бетермәү рөхсәт ителә.

<13>Катлаулы объект (мөлкәти комплекс составына керүче объект) төзелешенә рөхсәтнамә бирү очрагында капиталь төзелешнең һәрбер объектына карата тутырыла.

<14> Капиталь төзелеш объектының дәүләт кадастр исәбен гамәлгә ашыру өчен зарури өстәмә сыйфатламалар күрсәтелә, шул исәптән мәдәни мирас объектының, әгәр мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр үткәргәндә андый объектның конструкцияләре һәм ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгының башка бер сыйфатламаларына кагылынса.

<15> Капиталь төзелеш объектының адресы күрсәтелә, булса – дәүләт адреслы реестры нигезендә адрес бирү, адресны үзгәртү турындагы документларның реквизитларын күрсәтеп капиталь төзелеш объектының адресы; линияле объектлар өчен – Россия Федерациясе субъекты һәм муниципаль берәмлек исемнәре рәвешендә урнашу урынының тасвирламасы күрсәтелә.

<16> Проект документациясе экспертизасының уңай бәяләмәсе нигезендә расланган проект документациясендәге күрсәткечләрне исәпкә алып линияле объектка карата гына тутырыла. Бүлекнең бар графаларын да тутырып бетермәү рөхсәт ителә.

<17> Капиталь төзелеш объектының дәүләт кадастр исәбен гамәлгә ашыру өчен зарури өстәмә сыйфатламалар күрсәтелә, шул исәптән мәдәни мирас объектының, әгәр мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр үткәргәндә андый объектның конструкцияләре һәм ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгының башка бер сыйфатламаларына кагылынса.

<18>Төзелешкә рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогын тәгаенләү өчен нигезләр күрсәтелә:

- проект документациясе (бүлек);
- норматив хокукый акт (номер, дата, маддә).

<19>Төзелешкә элек бирелгән рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогын озайту очрагында тутырыла. Рөхсәтнамәне төзелешкә тәүге мәртәбә биргән очракта тутырылмый.

Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәтнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Административ регламентына кушымта №3

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе

___________________________________
(Ф.И.А.и.)
_________________________________
___________________________________
___________________________________
(физик зат өчен: гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм (булса) атасының исеме, гариза бирүченең яшәү урыны, гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документының реквизитлары;
юридик зат өчен: гариза бирүченең исеме һәм урнашу урыны, юридик затларның бердәм дәүләт реестрында юридик затның дәүләт
теркәве турында язмасының дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең таныклау номеры, гариза бирүче булып чит ил юридик заты торган очрактан гайре)
_________________________________
(гариза бирүче белән элемтә өчен почта һәм (яки) электрон почта адресы)

**техник хатаны төзәтү турында гариза**

______________________________________________муниципаль хезмәт
(күрсәтелгән хезмәтнең исеме)
күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

Язылган:_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________ Дөрес мәгълүматлар:_____________________________________________________________________________
_________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документка тиешле үзгәрешләрне кертүне үтенәм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу хакында карар кабул иткән очракта андый карарны җибәрүне үтенәм:

электрон документны E-mail_______________адресына җибәрү ярдәмендә; почта аша кәгазь йөрткечтә расланган күчермә рәвешендә түбәндәге адрес буенча: ____________________________________________________________________

Үземнең, шулай ук минем тарафтан тәкъдим ителә торган затның персональ мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системага салу, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), файдалану, тарату (шул исәптән тапшыру), мөстәкыйльлеген бетерү, блокадалау, персональ мәгълүматларны юкка чыгару, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләр), шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп автоматлаштырылган режимда эшкәртүгә риза булуны раслыйм.

Әлеге гариза белән раслыйм: гаризадагы минем шәхескә һәм минем тарафтан тәкъдим ителүче затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры киләләр, гаризаны бирү моментына бу документлар чын һәм дөрес мәгълүматларны үз эчләренә алалар.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфаты буенча ___________телефоны буенча сораштыруда катнашуга үземнең ризалыгымны бирәм.

______________ __________________ ( _________________)

(дата) (имза) (Ф.И.А.и.)

Кушымта
(белешмә)

**Үзидарәлек хезмәте күрсәтүгә җаваплы һәм аны үтәүгә контрольне гамәлгә ашыручы җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 88436122113 | balyk-bistage@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы | 88346123956 | Rauf.Hasanov@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 88436123956 | Irek.Hamidullin@tatar.ru |

**Балык Бистәсе муниципаль район Советы**

| Башлык | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башлык | **88436122113** | balyk-bistage@tatar.ru |